**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

| “КАРАЛДЫ” | **“КИЛЕШЕНДЕ”** | **“РАСЛАНДЫ”** |
| --- | --- | --- |
| МБ житәкчесе | «2 нче Алексеевск УГББМ» МБГБУ директор урынбасары | «2 нче Алексеевск УГББМ» МБГБУ директоры |
| ________Замалиева И.Х | _________Ягудина Л.Р. | _____________Липлянина Л.Н. |
| МБ утырышы беркетмәсе №_1__ _25__август 2016 ел | _27__ август 2016 ел | ___233______ номерлы боерыгы |
| | | _31__ август 2016 ел |

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Хөснетдинова Гөлия Сөләймановнаның**

**5 “Б” сыйныфы өчен татар теленнән**

**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралды
___1__номерлы беркетмә
__31___ август 2016 ел

2016-2017 уку елы

**Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

**Сыйныф:** 5 “Б”

**Укытучы:** Хуснутдинова Г.С.
**Уку планы буенча татар теленнән** 105 сәгать
**Атнага** 3 сәгать
**Сүзлек диктанты:2**
**Контроль эш:** 6.
**Программа** - Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р,Л. Малафеева., 2014 ел.

**Дәреслек -** Р.З.Хәйдәрова, Г.М. Ахметзянова “Татар теле”.Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек.Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2014ел.

Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.

Программа Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр**

Рус мәктәбенең 5 нче сыйныфларында укучы рус телендә сөйләшүче балаларга татар теленнән белем бирүнең төп максаты – Федераль дәүләт стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәниятлылык) компетенцияләр булдыру.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычлар куела:

- укучыларның 1-4нче сыйныфларда үзләштергән белемнәрен һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү;
- татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
- программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
- татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү, текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
- татар телендәге сөйләмне фонетик,лексик,грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;
- татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
- халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү;
- укучыларның татар телен өйрәнүгә ихтыяҗын арттыру. **Уку эшчәнлеген оештыра белү юнәлешендә**

1. Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
2. Эшне планлаштыра белү.
3. Эшнең дөреслеген тикшерү.
4. Эш сыйфатына бәя бирү.

**Китап, өстәмә мәгълүмат белән эш итү**

1. Дәреслек белән эш итә белү.
2. Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эш итә белү.
3. Төрле текстлар белән эш итү.
4. Белемнәрне системалаштыру өчен таблица, график , схемалардан файдалану.
5. Эчтәлекне аңлап, тиешле тизлектә, дөрес уку:
-уку елы башында -70-80 сүз;
-уку елы ахырында-80-90сүз;
6. Сүзлекләрдән файдалана белү.
7. Китапханәдә каталог белән эш итә белү.
8. Аудио-видео белән эш итә белү.

**Фикерләү белән бәйле күнекмәләр**

1. Уку мәсьәләсен куя белү.
2. Яңа теманы аңлауга мотив тудыру.
3. Танып белү активлыгын үстерү.
4. Төшенчә, термин,кагыйдә,закончалыкларны аңлап кабул итүкүнекмәләрен камилләштерү.
6. Тикшеренү ысуллары:
-модельләштерү;
-охшатып эшләү.
7. Логик алымнардан чагыштыру, анализ, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләре булдыру.

**Телдән һәм язма сөйләм үстерү һәм аралаша белү юнәлеше**

1. Телдән сөйләм:
-сорауны формалаштыра белү һәм тулы җавап бирә белү күнекмәсе;
-тәрҗемә итү күнекмәсе.
2. Язма сөйләм:
-күчереп язу;
-фикер йөртү элементлары кертеп, әзер план буенча бирелгән диалог, монолог язу
- изложение язу
*Уку елы башында 50 сүзле текст (язма күләме - 55-60 сүз), уку елы ахырында 60 сүзле текст.*

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

**Предмет нәтиҗәләре**:

– Укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә арашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
– “Татар теле һәм әдәбияты” предметынакарата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыруһәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштергә шартлар тудыру.

**Метапредмет нәтиҗәләре:**

Төп белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбиятын укыту, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль

тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыругахезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алукүнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
– ихтыяр көче,максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Шәхси нәтиҗәләр:**

Төп гомуми белем бирү баскычын тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

"гаилә", "туган ил", "мәрхәмәтлелек",төшенчәләрен кабул итү, "башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык", "кеше кадерен белү" кебек

**II.Укыту предметының эчтәлеге**

1. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре.
2. Тартым һәм килеш белән төрләнгән исемнәрнең берлек һәм күплек сандагы кушымчаларын аера белү.

3. Тамыр, кушма парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларның сөйләмдә кулланyын кабатлау.

**4.** Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе.

**5.** Сыйфат дәрәҗәләре белән таныштыру, аларны сөйләмдә куллану.

**6.** Микъдар, тәртип, җыю саннарын аера белү.

7. Мин, син, ул зат алмашлыкларының, төшем килешләрендә сөйләмдә куллана белү.

8. Зат алмашлыкларының урын-вакыт килешендә сөйләмдә куллану.

**9.** Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.

**10.** Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.

**11.** Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.

**12.** Боерык фигыльнең барлыкта һәм юклыкта 2нче затта төрләнешен сөйләмдә куллану.

**13.** Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану.

**14.** Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (кирәк, кирәкми, ярый, ярамый) белән сөйләмдә куллану

**15. Эшләргә телим –** төзелмәсен сөйләмдә куллану.

**16. Өчен, шикелле** бәйлекләрен сөйләмдә куллану.

**17.** Кереш сүзләрне **(минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, минем фикеремчә**) сөйләмдә куллану.

| Тематик эчтәлек, сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Без мәктәптә (27 сәг.)** Дәресләр расписаниесе, дәресләр әзерләү, өй эше эшләү. Билгеләр. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә, саклап тоту. Китапханәдә. | Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, санын, кирәклеген хәбәр итә белү (сорау), үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкдим итә белү. Беренче сентябрь–Белем бәйрәме турында сөйли белү. Дәресләр расписаниесе буенча нәрсә эшдәгәнне әйтә белү. Өй эшен әзерләү, әзерләмәүнең сәбәбен әйтә белү. Ни өчен яхшы, начар билгеләр алу турында сөйләшү. Уку-язу әсбаплары, аларны саклап тоту турында киңәш бирә белү. Китапханәчедән кирәкле китапларны сорап ала белү. |
| **Мин – өйдә булышчы (35 сәг.)** Без эти-әнигә булышабыз. Өйдәге эшләр. Без бергә эшлибез. Өй хезмәте өчен рәхмәт белдерү һәм мактау. Кем эшләми - шул ашамый. | Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү. Вакытны сорый, әйтә белү. Өйдә эшләгән эшләрне әйтә, сорый, куша белү. Эш эшләргә риза булуыңны, булмавыңны белдерү. Өй эшләрендә үзеңә булышырга, ярдәм итәргә сорый, нәрсә эшләргә кирәк икәнен әйтә белү. Кибеткә барырга куша, нәрсә алырга икәнен әйтә, сорый белү. Өйдәге эшләрне эшләргә киңәш бирә, яхшы эшләр өчен мактый белү.Өйдәге хезмәттә катнашуга карап, кешеләргә бәя бирә белү. |
| **Дуслар белән күңелле (24 сәг.)** Минем дустым бар. Дус була белү сыйфатлары. Дуслар белән итәгатьле сөйләшү. Дуслар, өлкәннәр белән телефоннан сөйләшү әдәбе. Дуслар белән туган көн үткәрү. Кибеттән ризыклар алу. Табын әзерләү. Табын янында үз-үзеңне тоту. | Дустыңның барлыгын, кемнәр белән дус икәнеңне, аларның нинди булуын әйтә белү. Кайда, кайчан дуслашкан, дусның нинди булуын, бергә нишләгәнне сөйли белү. Чын дусның авыр хәлдә калдырмавын, бер-береңә ярдәм итү турында сөйләшү. Дусларны телефоннан уйнарга чакыра, туган көнгә итагәтле чакыра белү. Дуслар белән туган көнгә әзерләнү, кибеттән ризыклар алу, кибетче белән сөйләшә белү. Татар халык ашларын, нәрсәләр ярату, яратмауны әйтә белү.Табын әзерләү турында сөйләшү. Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сөйли белү. |

| | |
|---|---|
| **Дүрт аяклы дусларыбыз (8 сәг.)**<br>Дүрт аяклы дусларның токым нары, кыяфәтләре, гадәтләре. | Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйләшә белү. Этләр турында кызыклы мәгълүмат әйтә белү. |
| **Без спорт яратабыз (8 сәг.)**<br>Тән әгъзалары. Табибта. Сәламәт булу кагыйдәләре.<br>Спорт белән шөгыльләнү. | Тән әгъзаларының исемнәрен, нәрсә авыртуын, авыртмавын табибка әйтә, сорый белү. Спорт төрләрен аера, үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны, нинди спорт түгәрәгенә йөргәнеңне, физкультура дәресендә нәрсә эшләгәнеңне әйтә белү. Сабантуйдагы милли уеннарны әйтә, Сабантуйга бару, катнашу турында сөйләшү. |

## 111.Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Дәрес темасы | Укучылар эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Яңа уку елы котлы булсын! | Схема буенча җөмләләр төзү. | 2.09 |
| 2. | Исәнләшү кагыйдәләре. | Үз хезмәтеңне оештыра белү. | 3.09 |
| 3. | “Мәктәп” темасына кергән лексик-грамматик материал. | Парларда эшли белү. | 5.09 |
| 4. | Исемнәрнең төшем һәм юнәлеш килешләрендә төрләнүе. | Лексик минимумны телдән тикшерү. Схема буенча җөмләләр төзи белү. | 9.09 |
| 5. | “Мәктәптә белем бәйрәме”текстын дагы лексик-грамматик материал. | Фронталь әңгәмә, индивидуаль тикшерү. | 10.09 |
| 6. | “Без хикәя сөйлибез”. “Дәүләт гимны”. | Хикәя төзи белү. | 12.09 |
| 7. | Кереш контроль эш. | Контроль дәфтәрләрдә эш. | 16.09 |
| 8. | Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнеше. | Таблица буенча эш, дәреслек, дәфтәр белән эш. | 17.09 |
| 9. | Тартымлы исемнәрнең сөйләмдә кулланылышы. | Парларда эшли белү, диалоглар төзү. | 19.09 |
| 10. | Исемнәрнең күплек санда тартым белән төрләнеше | Таблица белән эшли белү. | 23.09 |
| 11. | Боерык фигыль | Таблица белән эшли белү | 24.09 |
| 12. | Боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | Схемалар буенча җөмләләр төзи белү | 26.09 |
| 13. | Әдәпле сөйләм формалары. | Парларда эшли белү. | 30.09 |
| 14. | “Әдәпле сөйләшәбез”. | Парларда эшли белү. | 1.10 |
| 15. | Исемнәр | Таблица белән эшли белү | 3.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ясалышы. | | |
| 16. | “Китап - минем дустым, киңәшчем”. | Сәнгатьле уку | 7.10 |
| 17. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлык формасында зат-сан белән төрләнеше. | Аутентив материал белән эшли белү. | 8.10 |
| 18. | “Без дәрестә” | Уку, тәрҗемә итү, диалоглар төзү. | 10.10 |
| 19. | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасында зат-сан белән төрләнеше. | Язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. | 14.10 |
| 20. | Билгеле үткән заман хикәя фигыль. | Чагыштыра һәм гомумиләштерә белү( рус һәм татар телен). | 15.10 |
| 21. | “Олегның нигә кәефе юк?” тексты буенча лексик-грамматик материал. | Фронталь әңгәмә | 17.10 |
| 22. | “Олегның нигә кәефе юк?” тексты | Язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. | 21.10 |
| 23 | Тест “Без мәктәптә”. | тест | 22.10 |
| 24. | Хаталар өстендә эш. Сан төркемчәләре. | Хаталар өстендә эш эшләү | 24.10 |
| 25. | “Сан+исем” төзелмәсе. | Индивидуаль  тикшерү | 28.10 |
| 26. | “Без диктант язабыз**”.** | Уку, тәрҗемә итү, диалоглар төзү. | 29.10 |
| 27. | Без хикәя язабыз”. | Хикәя төзү. | 7.11 |
| 28. | “Иртәнге режимым” темасы буенча лексик-грамматик материал. | Яңа сүзләр өйрәнү, күнегүләр эшләү. | 11.11 |
| 29. | “Минем иртәнге режимым”. | Схема белән эшли белү | 12.11 |
| 30. | Сәгать ничә? | Төркемнәрдә, парларда эшләү. | 14.11 |
| 31. | “Минем көндәлек режимым”. | Хикәя төзи белү | 18.11 |
| 32. | Билгеле үткән | Чагыштыра һәм гомумиләштерә | 19.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | заман хикәя фигыль. | белү. | |
| 33. | “Мин –өйдә булышчы”.Сүзлек диктанты. | Сүзлек диктанты. | 21.11 |
| 34. | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. | Таблица белән эшли белү | 25.11 |
| 35. | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше | Таблица белән эшли белү | 26.11 |
| 36. | “Мәктәпкә киткәнче”,”Илнур белән Рәсимнең иртәнге режимы”. | Парларда һәм төркемнәрдә эшли белү. | 28.11 |
| 37. | Изложение «Минем режимым». | Изложение | 2.12 |
| 38. | Илнур, Рәсим образларына чагыштырма характеристика. | Чагыштыра һәм гомумиләштерә белү. | 3.12 |
| 39. | “Без киңәшләр бирәбез”. | Киңәшләр бирә белү. | 5.12 |
| 40. | Инфинитив. | Таблица белән эшли белү | 9.12 |
| 41. | “Без киңәшләр бирәбез”. | Киңәшләр бирә белү. | 10.12 |
| 42. | “Без нинди булышчылар?” | Парларда һәм төркемнәрдә эшли белү. | 12.12 |
| 43. | “Мин әниемне мактыйм”. | Җөмләләр төзү | 16.12 |
| 44. | “Рәсим” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | Яңа сүзләр өйрәнү,җөмләләр төзү | 17.12 |
| 45. | Контроль тест№2 “Мин өйдә булышчы”. | тест | 19.12 |
| 46. | Хаталар өстендә эш.“Рәсимнең хатасы”. | Хаталар өстендә эш. | 23.12 |
| 47. | “Без өйдә булышырга телибез” | Монологик сөйләм | 24.12 |
| 48. | Без өйдә булышабыз. | Диалоглар төзү. | 9.01 |
| 49. | Теманы кабатлау. | Күнегүләр эшләү. | 13.01 |

<table>
<tr><td>50.</td><td>Ю.Ермолаевның “Ике пирожный” хикәясендәге лекск-грамматик материал.</td><td>Мөстәкыйль эшли белү.</td><td>14.01</td></tr>
<tr><td>51.</td><td>Ю.Ермолаевның “Ике пирожный” хикәясе.</td><td>Таблица белән эшли белү</td><td>16.01</td></tr>
<tr><td>52</td><td>“Без сәхнәдә уйныйбыз”.</td><td>сәхнәләштерү</td><td>20.01</td></tr>
<tr><td>53</td><td>Образларга бәя бирү.</td><td>Образларга бәя бирү</td><td>21.01</td></tr>
<tr><td>54</td><td>“Без хикәя язабыз”</td><td>Хикәя төзү</td><td>23.01</td></tr>
<tr><td>55</td><td>“Тавык,Тычкан һәм Көртлек”әкиятен дәге лексик-грамматик материал.</td><td>Парларда эшләү</td><td>27.01</td></tr>
<tr><td>56</td><td>“Ипи ничек пешә?</td><td>Таблица белән эшли белү</td><td>28.01</td></tr>
<tr><td>57</td><td>“Без әкият сөйлибез”.</td><td>Монологик сөйләм.</td><td>30.01</td></tr>
<tr><td>58</td><td>“Без сәхнәдә уйныйбыз”.</td><td>Сәхнәләштерү.</td><td>3.02</td></tr>
<tr><td>59</td><td>Билгесез үткән заман хикәя фигыль.</td><td>Чагыштыра һәм гомумиләштерә белү.</td><td>4.02</td></tr>
<tr><td>60</td><td>Билгесез үткән заман хикәя фигыль.</td><td>Сөйләмдә куллану, күнегүләр эшләү.</td><td>6.02</td></tr>
<tr><td>61</td><td>“Без әкиятләр язабыз”.</td><td>Хикәя төзү.</td><td>10.02</td></tr>
<tr><td>62</td><td rowspan="2">“Минем дусларым” темасы буенча лексик-грамматик материал.</td><td></td><td>11.02</td></tr>
<tr><td>63</td><td>Парларда һәм төркемнәрдә эшләү.</td><td>13.02</td></tr>
<tr><td>64</td><td>“Минем дусларым бар”.</td><td>Дусларың турында сөйли белү.</td><td>17.02</td></tr>
<tr><td>65</td><td>Сыйфат дәрәҗәләре. Сүзлек диктанты.</td><td>Сүзлек диктанты</td><td>18.02</td></tr>
<tr><td>66</td><td>Сыйфат дәрәҗәләренең сөйләмдә кулланылышы.</td><td>Күнегүләр эшләү.</td><td>20.02</td></tr>
<tr><td>67</td><td>“Язгы каникул” хикәясендәге лексик-грамматик</td><td>Таблица белән эшли белү</td><td>24.02</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | материал. | | |
| 68 | “Язгы каникул” хикәясе. | Текст белән эшләү. | 25.02 |
| 69 | Боеруны һәм үтенечне белдерү. | Ситуатив күнегүләр эшләү. | 27.02 |
| 70 | “Без матур сөйләшәбез”. | Парлардаэшли белү. | 3.03 |
| 71 | “Дусларга ни өчен күңелсез?” | Күнегүләр эшләү, язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү. | 4.03 |
| 72 | “Без хикәя язабыз”. | Хикәя төзү. | 6.03 |
| 73 | Телефоннан сөйләшү этикеты. | Әңгәмә кору. | 10.03 |
| 74 | Сочинение “ Минем дустым”. | Сочинение. | 11.03 |
| 75 | Татар халык ашлары.“Мин нәрсә ярatam?” | Күнегүләр эшләү. | 13.03 |
| 76 | Контроль диктант. | диктант | 17.03 |
| 77 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. | Парларда эшли белү. | 18.03 |
| 78 | “Без туган көнгә әзерләнәбез”. | Парларда эшли белү | 31.03 |
| 79. | “Гүзәл Ләйсәннәрдә”хикәясе. | Текст белән эшләү. | 1.04 |
| 80. | “Без табын әзерлибез” | План төзү. | 3.04 |
| 81. | “Мин салатлар ясыйм”. | Рецепт язу. | 7.04 |
| 82 | Контроль тест №3 | тест | 8.04 |
| 83 | Хаталар өстендә эш.“Туган көндә”. | Хаталар өстендә эш | 10.04 |
| 84 | “Табын янында” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | Яңа сүзләр өйрәнү, җөмләләр төзү. | 14.04 |
| 85 | “Табын янында” хикәясе. | Текст өстендә эш. | 15.04 |
| 86 | “Без табын янында” | Күнегүләр эшләү. | 17.04 |
| 87 | «Дуслар белән күңелле» | Индивидуаль тикшерү. | 21.04 |
| 88 | Дүрт аяклы дусларыбыз. | Биремнәр эшләү. | 22.04 |
| 89 | Дүрт аяклы дусларыбызның гадәтләре. | Төркемнәрдә эшләү. | 24.04 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 90 | Контроль эш<br>Дүрт аяклы дусларыбыз | Контроль эш | 28.04 |
| 91 | Дүрт аяклы дусларыбыз,аларның токымнары. | Төркемнәрдә эшләү | 29.04 |
| 92 | “Минем дүрт аяклы дустым” | Хикәя төзү. | 1.05 |
| 93 | “Минем дүрт аяклы дустым” | Диалоглар төзү. | 5.05 |
| 94 | Мин, син зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше. Х.Гардановның “Акыллы Карабай” хикәясендәге лексик-грамматик материал. | Яңа сүзләр өйрәнү, җөмләләр төзү. | 6.05 |
| 95 | Контроль тест№4 « Дуслар белән күңелле” | Контроль тест | 8.05 |
| 96 | Хаталар өстендә эш.<br>“Мин авырыйм” | Хаталар өстендә эш. | 12.05 |
| 97 | Еллык контроль эш | контроль эш | 13.05 |
| 98 | Хаталар өстендә эш.Спорт төрләре. | Хаталар өстендә эш | 15.05 |
| 99 | “Мин нинди спорт төре белән шөгыльләнәм?” | Монологик, диалогик сөйләм. | 19.05 |
| 100 | “Сәламәт булу өчен нишләргә кирәк?” | Җөмләләр төзү, күнегүләр эшләү. | 20.05 |
| 101 | Сабан туе программасының афишасы. | Парларда һәм төркемнәрдә эш. | 22.05 |
| 102 | Үткәннәрне кабатлау | Грамматик биремнәр. | 26.05 |
| 103 | Кабатлау | Грамматик биремнәр | 27.05 |
| 104 | Үткәннәрне кабатлау. | Рәсемнәр белән эшләү. | 29.05 |
| 105 | Йомгаклау. | Кабатлауга биремнәр. | 30.05 |

Пронумеровано, прошнуровано
и скреплено печатью
Всего: 12(двенадцать) листов
Учитель: Хуснутдинова Г.С.

средняя
общеобразовательная
школа №2
с углубленным изучением
отдельных предметов»
ИНН 1605001185